**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы Инвестиция советы составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-914 номерлы, 2013 елның 20 мартындагы ПУ-242 номерлы, 2013 елның 29 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2013 елның 8 августындагы ПУ-717 номерлы, 2014 елның 29 апрелендәге ПУ-440 номерлы, 2014 елның 27 августындагы ПУ-826 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-984 номерлы, 2016 елның 29 июнендәге ПУ-553 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2018 елның 4 сентябрендәге ПУ-612 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-90 номерлы, 2019 елның 12 октябрендәге ПУ-619 номерлы һәм 2020 елның 28 мартындагы ПУ-206 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Инвестиция советы) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Инвестиция советы составыннан Ф.М. Хәнифовны чыгарырга;

б) Инвестиция советы составына Айзатуллин Марат Мансур улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын кертергә;

в) Инвестиция советы әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Ш. Фәрдиевның – «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

М.Р. Шаһиәхмәтовның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

(Печать: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ГОМУМИ БҮЛЕК • ОБЩИЙ ОТДЕЛ)

Казан, Кремль
2020 ел, 26 ноябрь
№ ПУ-782